**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

20.07.2016 668-п

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгында дәүләт гражданлык
хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә
карата таләпләр үтәлеше һәм
мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу
турында комиссия хакында

2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” № 79-ФЗ Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге “Федераль дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында” № 821 Указы, 2003 елның 16 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында” № ПУ-569 Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмә расларга (кушымта булып килә).

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенә (Г.Р. Хәннанова) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң шушы боерык белән Министрлыкның барлык структур бүлекчәләрен таныштырырга.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесенә – коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы затка (Г.Р. Аблеева) Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң 7 көнлек срокта шушы боерыкны Татарстан Республикасының “Татарстан

Республикасының рәсми порталы” дәүләт мәгълүмат системасы составындагы Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы сайтында, “Коррупциягә каршы көрәш” бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар
министрлыгының 2016
елның 20 июльдагы
№ 668-п боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүнамәләрнең керү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба – Министрлык) Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүнамәләрнең керү тәртибе (алга таба – Тәртип) кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә түбәндәгеләрнең керү процедурасын регламентлый:

Министрлыкта министр боерыгы белән расланган, Министрлыкта аларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлегенә кертелгән вазифаны биләгән гражданнан, дәүләт хезмәтеннән куылган көннән башлап ике ел узганчыга кадәр, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүгә яисә хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада эшләр башкаруга ризалык бирелү турында мөрәҗәгате, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәлеге буенча аерым функцияләре аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

дәүләт гражданлык хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

дәүләт гражданлык хезмәткәренең, территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, акчалата акча чаралары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган чит ил дәүләтенең вәкаләтле органнары тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә

салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле сәбәпле, яки аның ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар булу сәбәпле, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” № 79-ФЗ Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гаризасы.

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең вазифаи вәкаләтләрне башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында белдерүнамәсен кертү һәм карап тикшерү тәртибе министрның 12.02.2016 № 119-п боерыгы белән җайга салына.

2. Гражданның мөрәҗәгате һәм дәүләт гражданлык хезмәткәренең гаризалары шушы Тәртипкә карата 1, 2 һәм 3 кушымталарга туры китереп, язмача рәвештә төзелә һәм министрга оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге аша җибәрелә.

3. Министр (аның вазифаларын башкаручы зат) өч эш көне дәвамында мөрәҗәгатьне (гаризаны) беренчел карап тикшерү өчен коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Министрлыкның Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе мөрәҗәгатьне (гаризаны), аңлатмаларны һәм башка материалларны Министрлыкның Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турындагы нигезләмәгә туры китереп карап тикшерә.

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигый ресурслар министрлыгының
Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт
тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм
мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча
комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булган
мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм
белдерүнамәләрнең керү
тәртибенә карата 1 кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм
табигый ресурслар министрына
___________________________________
кемнән_____________________________
(вазифасының аталышы)
___________________________________
___________________________________
(Ф.И.А., телефон номеры)

Объектив сәбәпләр аркасында хатынымның (иремнең) һәм
балигълык яшенә җитмәгән балаларымның керемнәре, милеге һәм мөлкәти
характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру
мөмкинлегем булмавы турында
ГАРИЗА

Минем_____________________________________________________________
(Комиссия белешмәләрне тапшырмауның объектив һәм хөрмәткә лаек характерга ия булуы
___________________________________________________________________
___турында нәтиҗә чыгара алсын өчен кирәкле булган барлык сәбәпләр һәм шартлар
күрсәтелә)
___________________________________________________________аркасында
___________________________________________________________________
(хатынымның, иремнең һәм (яки) балигълык яшенә җитмәгән балаларымның Ф.И.А.,
туган көннәре)
керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлегем булмавы турында хәбәр итәм.
Гаризага түбәндәге өстәмә документларны терким (булган очракта):
___________________________________________________________________
(өстәмә материаллар күрсәтелә)
Аталган белешмәләрне тапшыру буенча гражданлык хезмәткәре тарафыннан күрелгән чаралар:
___________________________________________________________________
Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесенең астына сызарга).

| _____________ | __________________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигый ресурслар министрлыгының Дәүләт
гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә
карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр
каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе
утырышын үткәрү өчен нигез булган
мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның
һәм белдерүнамәләрнең керү
тәртибенә карата 2 кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм
табигый ресурслар министрына

___________________________________

кемнән____________________________

(вазифасының аталышы)

___________________________________

___________________________________

(Ф.И.А., телефон номеры)

ГАРИЗА

Минем________________________________________________________________
_

(Комиссия федераль закон таләпләрен үтәмәүнең объектив һәм хөрмәткә лаек характерга ия булуы

_________________________________________________________________________

___турында нәтиҗә чыгара алсын өчен кирәкле булган барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________аркасында

территориясендәге чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) булган, акчалата акча чаралары һәм кыйммәтләр саклана торган һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган чит ил дәүләтенең вәкаләтле органнары тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле сәбәпле, яки ихтыярыма яки хатынымның (иремнең) һәм балигъ булмаган балаларымның ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар булу сәбәпле, 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" № 79-ФЗ Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегем булмавы турында хәбәр итәм.

Гаризага түбәндәге өстәмә документларны терким (булган очракта): _________________________________________________________________________

(өстәмә материаллар күрсәтелә)

Күрелгән чаралар:__________________________________________________

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесенең астына сызарга).

| ________________ | ______________________ | ______________________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигый ресурслар министрлыгының Дәүләт
гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә
карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр
каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе
утырышын үткәрү өчен нигез булган
мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның
һәм белдерүнамәләрнең керү
тәртибенә карата 3 кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм
табигый ресурслар министрына
________________________________________
кемнән__________________________________
(Ф.И.А., адресы, телефон номеры)

Коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифа
биләүгә яки хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамә шартларында
коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада эшләр башкаруга
ризалык бирелү турында
МӨРӘҖӘГАТЬ

Мин,____________________________________________________________
(Ф.И.А.)
Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында ____ башлап_______ кадәр ___________________________________________________
(вазифаның аталышы)
дәүләт гражданлык вазифасын биләдем, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясы нигезендә_________________________________________________________________
(коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманың аталышы)
____________________________________________________________________
(граждан биләргә теләгән вазифаның аталышы)
вазифасын биләүгә яки гражданлык-хокукый шартнамә шартларында
____________________________________________________________________
(коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманың аталышы)
____________________________________________________________________
(граждан башкарачак эшләрнең төре, хезмәтнең аталышы)
эшләр башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирелүне сорыйм.

Минем вазифаи бурычларыма түбәндәгеләр керәчәк (минем тарафтан башкарылачак эш түбәндәгеләрне үз эченә алачак):
____________________________________________________________________
(гражданлык-хокукый шартнамәсен төзегән очракта вазифаи бурычларга кыскача тасвирлама, башкарыла торган эшнең характеры)
Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр

каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесенең астына сызарга).

| | | |
|---|---|---|
| _________________ (дата) | _______________________ (имза) | ________________________________________ (имзаның аңлатмасы) |